**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Урта Комар авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2023 елның 10 ноябре** **№5**

**«Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Түбән Комар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2023 елның 23 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Түбән Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Комар авылы, Тау ягы урамы, 6Б йорты адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә.

2. 2023 елның 23 ноябренә 18 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Түбән Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Комар авылы, Тау ягы урамы, 6Б йорты адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә.

3. 2023 елның 23 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Урта Комар авыл җирлегенең Түбән Комар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Түбән Комар авылы, Тау ягы урамы, 6Б йорты адресы буенча урнашкан күпфункцияле үзәк бинасында үткәрергә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Урта Комар авыл җирлеге Түбән Комар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокны хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, локаль сугышларда һәм Украинада махсус операция барышында һәлак булганнарның гаиләләреннән, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Түбән Комар авылына янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру. Проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; Янгын рукавлары, стволлар, переходниклар һәм колонкалар сатып алу. Килешү буенча эш өчен түләү;
- Түбән Комар авылы юл полотносын торгызу;
- тирәннән суырту насосы сатып алу һәм урнаштыру;
- су трассасын ремонтлау һәм тирәннән суырту насосын алыштыруга килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

-ремонт, урамнарны яктырту өчен яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру. Проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр өчен түләү;

- Түбән Комар авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм җәй көне территорияне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ».

5. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

6. Халык җыенын үткәрүгә җаваплы итеп Урта Комар авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

7. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

8. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Урта Комар авыл җирлеге башлыгы: С.В.Федоров

СОВЕТ СРЕДНЕКУМОРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КОМАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ОГРН 1021607752891
ИНН 1623001690